| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БАВЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

24.08.2026 ел Баулы шәһәре №97

Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 9 декабрендәге 182 номерлы карары белән расланган ваклап сату базарын оештыру хокукына рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә туристлык эшчәнлеге нигезләре турында» Федераль законның 4 һәм 19.5 статьяларына һәм «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» Федераль законның 15 һәм 15.1 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 2025 елның 29 декабрендәге 552-ФЗ номерлы Федераль законнары нигезендә Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 9 декабрендәге 182 номерлы карары белән расланган ваклап сату базарын оештыру хокукына рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

2 «Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты» бүлегендә:

2.5.1. пунктының 1) пунктчасын «йә шәхесне таныклаучы башка документны Россия Федерациясе законнары нигезендә яисә дәүләт хезмәтләре күрсәтүче органнарда, муниципаль хезмәтләр күрсәтүче органнарда, күпфункцияле үзәкләрдә 2022 елның 29 декабрендәге 572-ФЗ номерлы Федераль законның 9, 10 һәм 14 статьяларында каралган мәгълүмат технологияләрен кулланып, идентификацияләү һәм аутентификацияләү юлы белән яисә шәхесне таныклаучы башка документны гамәлгә ашыру турында «Физик затларны биометрик персональ белешмәләрдән файдаланып идентификацияләү һәм (яисә) аутентификацияләү, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында»;» сүзләре белән тулыландырырга;

2.14.2. пунктында

1) пунктчада «башка оешмалар),» сүзләреннән соң «туристлык эшчәнлеге турында Россия Федерациясе законнары нигезендә классификацияләнергә тиешле туристлык индустриясе объектларына («Кунак йортлары хезмәтләрен күрсәтү буенча эксперимент үткәрү турында» 2025 елның 7 июнендәге 127-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә урнаштыру чараларына караган объектлардан һәм аларда күрсәтелә торган хезмәтләрдән тыш)» (алга таба - туристлык индустриясе объектлары),» сүзләрен өстәргә.;

3) пунктчада «транспорт инфраструктурасы,» сүзләреннән соң «туристлык индустриясе объектлары,» сүзләрен өстәргә.;

4) пунктчада «,туристлык индустриясе объектларында» сүзләрен өстәргә.;

5) пунктчада «транспорт инфраструктуралары» сүзләреннән соң «, туристлык индустриясе объектларына» сүзләрен өстәргә.;

7) пунктта «транспорт инфраструктуралары» сүзләреннән соң «, туристлык индустриясе объектлары» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карар  2026 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында  (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисадый үсеш буенча урынбасарына йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы                                        И.И. Хөснуллина